Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советының кырык алтынчы утырышы

Күн авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2018 елның 20 сентябре № 102

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы “Җирле референдум турында” законының 12, 17 статьялары, Күн авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советы КАРАР чыгарды:

1. Күн авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итәргә: “2019 елда яшәү урыны Күн авыл җирлеге чикләрендә урнашкан, 18 яшькә җиткән һәр Россия Федерациясе гражданыннан 500 сум үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны киләсе эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме:

- Күн авылы эчендәге юлларны төзекләндерү;
- Күн авылыда Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булганнарга һәйкәл кую;
- Кызыл Яшьләр авылында су белән тәэмин итү челтәрләре төзелешен дәвам итү
- Әлбәден авылының Колхоз урамындагы юлларны ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча акча экономияләнгән очракта, Күн авыл җирлеге башкарма комитетына референдум тарафыннан билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә,

ӘЙЕ ЮК”.

2. Әлеге карарны Күн авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Күн авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Баһауов